СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан,
Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы,
ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б.,
Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru,
www.saby.tatarstan.ru

№ 21 от 11.11.2025№ _________ _________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты структурасын раслау
турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 22 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 29 һәм 43 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Чик санын билгеләргә:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты 38 штат берәмлеге күләмендә;

– Муниципаль казна учреждениеләре 14 штат берәмлеге күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2021 елның 15 декабрендәге 105 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Кәримовка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

Саба муниципаль районы Советының
2025 елның _____________карары белән
РАСЛАНГАН

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
СТРУКТУРАСЫ**

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;
2. Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге начальнигы;
3. Башкарма комитет Җитәкчесенең инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары - Саба муниципаль районының инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү бүлеге башлыгы;
4. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;
5. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе;
6. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе;
7. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге;
8. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты оештыру бүлегенең документлар әйләнеше секторы;
9. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар эше буенча секторы;
10. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык секторы;
11. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге;
12. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;
13. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;
14. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;
15. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлеге;
16. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү бүлеге;
17. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге;
18. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге;
19. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлеге;
20. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге;
21. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе ;
22. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.